Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Иске Пукшинер авылы

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март 2024 ел №8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Иске Пукшинер торак пунктында узган халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Иске Пукшинер торак пунктында узган гражданнар җыелышында 2023 елның 19 ноябрендә кабул ителгән 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

су белән тәэмин итү һәм суны чистарту системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм төзәтү:

- Иске Пукшинер авылын су белән тәэмин итү системасын төзәтү;

- Иске Пукшинер авылын су белән тәэмин итү системасы скважинасының санитар-саклау зонасын төзекләндерү.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев